КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 21

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм башкару турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итү турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм башкару тәртибен, Хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итү нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә һәм кошчылык фабрикаларында дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авырулары булганда хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе турындагы тәгълимнамәне раслау хакында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алып юк итүне башкару кирәклеге турында» 2021 елның 11 гыйнварындагы чыг-1 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы территориясендә Африка дуңгыз чумасы чыгу урыннары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә,

аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге ПУ-912 номерлы Указының 2 нче пунктындагы «а» һәм «б» пунктчалары белән билгеләнгән территориядә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне башкарырга.

2. Бу карарга теркәлгән Хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне башкару буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алып юк итүне башкару буенча махсус комиссиягә бу карарның 1 нче пункты белән күздә тотылган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 21 гыйнвар, 21 нче
карары белән расланды

Хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын
алып юк итүне башкару буенча махсус комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Махсус комиссия әгъзалары: | |
| Галиев Эмиль Эдуард улы | Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гатин Идрис Мөдәррис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Исламов Фоат Габбас улы | «Зәй районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджетное учреждение башлыгы |
| Ногманов Илдар Нургали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |
| Хаҗиева Ирина Нурулла улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган дәүләт ветеринария инспекциясенең Түбән Кама территориаль бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча). |

_______________